Загидуллин И. **Уроки прошлого**. // Мирас, 2001. – № 3. (на татарском языке)
История празднования в России взятия Казанского ханства.

*Заһидуллин И*. Тарих фәннәре кандидаты.

**Үткән тарих гыйбрәтле** // Мирас, 2001. – №3.

2002 елда Казан ханлыгын Мәскәү дәүләте басып алуга 450 ел була. Бу тарихи вакыйга, әлбәттә, билгеләп үтелер. Русиядә дә, Татарстанда да. Билгеле булганча, 2005 елда Казан шәһәренең 1000 еллыгы Россия президенты указы нигезендә бәйрәм ителәчәк. Казанны алу юбилее уңаеннан указ булырмы, юкмы? Тарихи вакыйга ничек билгеләп үтелер? Бу сорауларга җавап бирүне хакимияткә калдырып, мин патша Русиясендә Казан алынуны бәйрәм итү тарихын кыскача язып китәргә уйлыйм.

Казан ханлыгын җимерү Мәскәү хөкүмәтенә элеккеге Алтын Урда җирләрендә үз дәүләтләре белән яшәп ятучы төрки халыкларны буйсындырырга, Рәсәйне тагын да көчәйтергә мөмкинлек ача. Казан ханлыгын яулагач, Мәскәү дәүләте күпмилләтле Русиягә әверелә башлый.

Иван Грозныйның бу җиңүе патша Русиясе чорында басылган тарихи хезмәтләрдә, дәреслекләрдә киң яктыртылган, югары бәя алган, бик тәфсилләп язылган.

Казан ханлыгын җиңү вакыйгасы Иван Грозныйның үзе тарафыннан ук мәңгеләштерелгән икән. Казанны Мәскәү гаскәре 2 октябрьдә (иске стиль белән) ала. 4 октябрьдә зур тантана (крестный ход) белән патша шәһәргә тәүге тапкыр аяк баса. Шул ук көнне агачтан салынган Киприан, Устина һәм Спасе чиркәүләре ачыла. Моңардан тыш, татар ханнары сарайлары янында патша Благовещенск чиркәве урынын билгели. 6 октябрь көнне аны ачуда катнаша.

Бу гыйбадәтханәләр ханлыкның башкаласын буйсындыру хөрмәтенә һәйкәлләр генә түгел, ә татар Казанында урыслар корган беренче биналар да була.

Казан өчен барган сугышта һөҗүм итүчеләр ягыннан да, шәһәрне саклаучылар ягыннан да күп кеше һәлак була. Мәскәүлеләр, үз сугышчылары мәетләрен җыеп, крепостьтан 1,5 чакрым читтә Казансу елгасы буенда туганнар каберлеге – уртак зур каберлек казып, православие йоласы белән зурлап җирлиләр. Шушы ziratны кадерләп карап тору һәм һәлак булган сугышчылар рухына панихидалар үткәрү өчен каберлек белән янәшә җирләрне Иван IV Успен монастырена бүләк итә. Бу вакытта әле шәһәрдән читтәге җирләр урыслар контролендә булмый. Каберлек янында часовня төзелә. Бу монастырь да Казан алынуга бер һәйкәл. Дөрес, 1559 елда язгы ташу вакытында Казансу буенда урнашкан монастырь су эчендә калгач, ул Елантауга күчерелә. Аның исеме дә озыная – Успен Елантау монастыре.

1556–1559 елларда патша фәрманы белән Мәскәүдә, Кызыл мәйданда, Казан ханлыгын җимерү хөрмәтенә бик үзенчәлекле архитектурага ия Покров соборы төзелә. Халык арасында бу чиркәү күбрәк Василий Блажен-ный соборы исеме белән таныла.

Шулай итеп, Иван Грозный үзе исән чакта Казан ханлыгын җиңү хөрмәтенә 5 һәйкәл төзеткән икән. Аларның барысының да гыйбадәтханә рәвешендә булуына гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки урта гасырларда рәсми идеология, мәдәният чиркәү тәгълиматы кысаларында яши.

Башкаланы югалткач та, элекке ханлыкта яшәгән халыклар дәүләтне кабат торгезү уе белән яналар. 1552–1557 елларда аларның Мәскәү гаскәрләре белән сугышулары Русия тарихында «Казанская война» дип атала. Чынлыкта ул дәүләтен кире кайтару өчен татарларның Ватан сугышы була.

Баш күтәрүчеләргә каршы тору һәм шәһәрне ныгыту максатында, 1555 елда ак таштан дивар корыла башлый. Шул елны Спасе чиркәве Кремльнең иң зур башнясына – Спасе башнясына күчерелә.

1595 елгы зур янгын агачтан эшләнгән Киприан һәм Устина чиркәвен юкка чыгара. 1596 елны аның урынына таштан чиркәү салына.

Благовещенск чиркәвен таштан 1561–1562 елларда Казан епархиясенең беренче архиепископы Гурий төзетә.

XVI гасырның икенче яртысы – ХУП гасырларда урыс хәрби-феодаль колонизациясе вакытында элекке Казан ханлыгы җирләрендә яңа крепость-шәһәрләр, чиркәү-монастырьлар төзелә, авыллар оеша. Бу – бик еш кына җирле халыкларны яшәгән урыннарыннан күчерү хисабына эшләнә. Элекке ханлык җирләре акрынлап Русия җирләре кыяфәтен ала бара. Православие дин әһелләре шушы төбәкнең тарихын булдыру турында кайгырталар. Патриарх Иов Казан митрополиты Гермоген үтенече нигезендә 1592 елның 3 февралендә карар кабул итә:

1. Ел саен Казан епархиясендәге барлык чиркәү-монастырьларда Покров бәйрәменнән соң килә торган беренче шимбәдә (Мәскәү гаскәрләре Казанга соңгы һөҗүм ясаган көнне) Казанны алганда һәм аннан соңгы татарлар белән сугышларда һәлак булган «батырларны» искә алу тәртибен кертергә (хәзергечә әйтсәк – хәтер көне була инде. – И. З.).

2. «Казан батырларының» һәм «Казан изге җәзаланучыларының» (мучениклар) исемнәрен (имеш, ислам диненә күчәргә теләмәгән өчен татарлар 1529 елда урыс әсире Иоанны үтергәннәр, ә 1552 елда – ислам диненнән ваз кичеп чукынган өчен Стефан һәм Петрны. Сүз шулар турында бара. Батырлыклары өчен алар өчесе дә рус православие чиркәвенең «изгеләре» исемлегенә кертеләләр) урыс чиркәвенең православие атнасында укыла торган зур синодигына язарга;

3. «Казан изге җәзаланучыларын» искә алу өчен махсус көн билгеләргә (Гермоген ул көнне 24 гыйнварга билгели).

Шулай итеп, Казанны алганда һәм ханлыкны буйсындырганда һәлак булган урыс сугышчыларын 1592 елдан башлап епархиянең барлык чиркәүләрендә панихида үткәреп искә ала башлыйлар. Елга бер тапкыр бу «батырларның» исемнәре Русия чиркәүләрендә дә яңгырый. Шушы рәвешле 1917 елга кадәр дәвам итә. Казанны алганда үтерелгән «урыс батырларының» исемнәре хәзер дә билгеле: бу исемлек XIX гасырда күп тапкырлар бастырыла (кара: Имена победителей Казани и прочих особ, поминаемых при отпевании панихид в Зилантовом монастыре и в Памятнике//Гавриил, архимандрит. Историческое описание памятника, сооруженного в воспоминание убиенных при взятии Казани воинов на Зилантовой горе – Казань, 1833.– С. 32–45).

Чиркәү тарафыннан рәсми рәвештә расланган искә алу тәртибе Казан ханлыгын яулаганда үлеп калган урыс сугышчыларының батырлыгын дәүләт тарафыннан тану һәм исемнәрен мәңгеләштерү була. Әйткәнебезчә, дәүләт идеологиясен бу чорда тулысы белән чиркәү билгели. Русия империясе күп сугышлар алып барган урыс сугышчыларының сөякләре, каберләре элекке Советлар Союзының төрле төбәкләрендә сибелгән, югалган. Аларның исемнәре дә сакланмаган. Казанны яулаучылар бу яктан бәхетле булганнар. Исемнәре билгеле һәм аларны һәрвакыт Русиядә «батырлар» дип хөрмәтләгәннәр, искә алганнар. Дөрес, бу исемлек тулы түгел, аны митрополит Гермоген 1580 еллар ахырында – 1890 еллар башында кешеләрдән сорашып һәм сакланган язмаларга нигезләнеп төзегән. Урта гасырлар өчен мондый исемлекне төзү үзе үк зур вакыйга була. Күрәбез, патша хөкүмәте Казанны алганда татарлар тарафыннан үтерелгән урыс «батырларының» исемнәрен кадерләп саклый белгән.

1555 елны төбәктә епархия оештыру һәм мөселманнарны чукындыру өчен Казанга архиепископ Гурий, аның хезмәттәшләре Варсонофий һәм Герман, шулай ук бер төркем православие дин әһелләре җибәрелә.

Чиркәү рухани «батырларны» изгеләштерү һәм исемнәрен мәңгеләштерүдә зур эш башкара. 1592 елда Казан архиепископы Германның (1564–1567) сөякләре Зөя шәһәрендә үзе архимандрит булган чорда төзеткән Успен монастыре чиркәвенә кайтарыла һәм ул «изге могҗиза ясаучы» итеп раслана.

Казан Кремлендә урнашкан Спасс-Преображен монастыренда төзелеш эшләре башлану сәбәпле, бередә җирләнгән Казан архиепископы Гурий (1555–1563) һәм епископ Варсонофий сөякләре, 1595 елның 4 октябрендә, Казанга патша Иван IV кергән көнне, казып алына һәм икенче урынга күчерелә. Чиркәү тарафыннан 4 октябрь изге Гурий һәм Варсонофийны искә алу көне булып раслана. 1630 елда архиепископ Гурий сөякләре заманында үзе төзеткән Благовещенск соборына күчерелә.

Иван IV нигез салган һәйкәлләрнең язмышы XIX йөздә ничек булган? 1801 елда Киприан һәм Устина чиркәве шәһәр җәмгыяте акчасына төзекләндерелә. Гыйбадәтханә 2 октябрь көнен билгеләп үтүдә зур роль уйный.

1815 елгы янгын Спасс чиркәвенә зур зыян сала. Кремль эчендәге чиркәүләр сәяси максатларда төзелгәнлектән, беркем дә чиркәүне яңартырга атлыгып тормый. Бу эшкә Кремль коменданты алына. Ләкин барыбер Спасс чиркәве чын мәгънәсендә гыйбадәтханә буларак эшләп китә алмый. 1836 елда Казанга килгән патша Николай Павлович, чиркәүнең буш торуын күреп, аны хәрбиләр карамагына бирергә боера. 1838 елдан башлап Спасс башнясына урнашкан чиркәү Казан гарнизоны солдатлары һәм шәһәрдә яшәгән офицерларның рухани-патриотик тәрбия үзәгенә әверелә.

Урта гасырларда төзелгән, зиннәтле бизәлгән, заманы өчен зур һәм мәһабәт булган Благовещенск соборы бинасы, мәйданы кечкенә булу сәбәпле, Казан епархиясе җитәкчелеген канәгатьләндерми башлый. 1830 елларда епархиянең баш чиркәве бинасының яңа проекты эшләнә. Яңа собор чиркәү бинасын җимереп, шуның урынына төзелергә тиеш була. Ләкин патша Николай I бу проектны расламый һәм 1561–1562 елларда төзелгән, Казан алынуга һәйкәл булган чиркәүне саклап кала. Дин әһелләре, аптырагач, Благовещенск чиркәвенә янкорма төзеп гыйбадәтханә мәйданын зурайталар.

Патшалар Александр I һәм Николай I Казанны яулау вакыйгасына зур әһәмият биргәннәр. Бу игътибар аларның эшчәнлекләрендә дә чагылыш таба. Моның ачык мисалы – татарларны җиңү хөрмәтенә Казанда һәйкәл төзү.

1811 елда архимандрит Амвросий, патша Иван IV Успен монастырена биргән грамотага нигезләнеп, аның Казанны алганда һәлак булган урыс сугышчылары истәлегенә һәйкәл салдыру турындагы васыяте хакында сүз кузгата. Туганнар каберлегенә һәйкәл кую нияте белән иганә акчасын җыю үткәрелә. Барлыгы 1,5 мең сум җыела.

Шушы суммага смета эшләнә, һәйкәлне биек таш багана формасында эшләргә уйлыйлар. Рәсемне раслату өчен башкалага, патша Александр I га җибәрелә. Казанны алу истәлегенә куелачак һәйкәлнең кыяфәте ул җиңүнең әһәмиятенә һич тә туры килмәвен күреп, император бу рәсемне кире кага һәм яңа һәйкәл проектын эшләргә боера. Бу җаваплы эш Санкт-Петербург архитекторы Н.Ф.Алферовка йөкләнә. 1812 елда император яңа проектны раслый. Александр I Рәсәйдә игълан ителгән иганә акчасын җыю исемлегенә беренче булып языла һәм 5 мең сум акча бирә. 1813 елның 23 июнендә тантаналы шартларда һәйкәлгә нигез салына. Иганә кампаниясен җыелдереп, архимандрит Амвросий ике тапкыр Мәскәү һәм Санкт-Петербургка бара, 30 мең сумга якын акча җыеп кайта. 1817 елны, «төрле сәбәпләр» нәтиҗәсендә иганә акчасы бетү сәбәпле, һәйкәл төзелеше туктала. Император Александр I ямьсез хәлдән котылу өчен кабат ярдәмгә килә.. Аның фәрманы нигезендә һәйкәл төзелеше тәмамланганчы дәүләт ел саен 5 мең сум акча биреп бара. Сметасы 80 мең сум булган һәйкәлне тезү 100135 сумга төшә. Иганә акчасы төп өч чыганактан: Александр I һәм патша гаиләсе әгъзалары (10 мең сум), дәүләт (30 мең сум чамасы) һәм сәүдәгәрләр, дворяннар, дин әһелләре, гади халык кесәсеннән җыела.

Һәйкәлне ачу тантанасы 1823 елның 30 августында бик купшы итеп оештырыла. Бу вакыйга Казан һәм губернаның барлык түрәләре, православие дин әһелләре, парадка тезелгән гаскәриләр, шәһәр халкы катнашында үтә. Һәйкәл ачылу хөрмәтенә туптан 101 тапкыр аталар.

Һәйкәл өске өлеше киселгән Мисыр пирамидасы формасында эшләнгән. Аның дүрт ягына коллонадалы порталлар куелган, һәр портал урта өлешендә икешәр колоннага утыртылган. Порталларга дүрт яктан да «1552 елда татарларны җиңү истәлегенә» дип язылган. Классик стиль белән Мисыр стиле үрелеп барган архитектура аны бик тиз арада Казан каласының үзенчәлекле йөзен билгеләүче бер әһәмиятле символга әверелдерә.

Һәйкәлнең архитектурасы да символларга бай. Әйтик, һәр яктан стенага беркетелгән калканнарда (алар икешәр) күпбашлы куркыныч гидра сурәтләнгән. Имеш, бу – Русиягә гел һөҗүм итеп торган татарлар кара кеченең рәсеме.

Һәйкәлнең эчендә чиркәү урнашкан. Гыйбадәтханә дорик стильдәге колонналар һәм пилястралар белән бизәлгән, һәйкәлнең ярым караңгы подвалында зур ящиктә (1832 елдан – зур матур табутта) фундамент казыганда чыккан урыс сугышчылары сөякләре тутырылган була. Стенага шәм беркетелгән, аның өстендә распятие куелган.

Урыс сугышчылары кабере өстенә салынса да, бу һәйкәл Казан ханлыгын җиңү хөрмәтенә төзелгән.

1823 елдан тарихи вакыйганы билгеләп үтү тәртибе яңа элементлар белән баетыла, һәйкәл төзелгәнче, гадәттә 2 октябрь көнне урыс сугышчылары зиратында епархия җитәкчесе гайбадәт кыла. Панихида Успен монастыре чиркәвендә дә үтә. Кремльдә Благовещенск соборыннан Спасо-Преображенск монастырена крестный ход, Киприан һәм Устина чиркәвендә изгеләр Киприан һәм Устина хөрмәтенә гыйбадәт кылу була.

Һәйкәл төзелгәч исә аның чиркәвендә 2 октябрь көнне патша Иван Грозный һәм һәлак булган урыс сугышчылары истәлегенә панихида, аннан соң подвалга төшеп, Казанны алган «православие гаскәре» хөрмәтенә гыйбадәт («вечная память») кылына. Дини ритуал чиркәүдә патша һәм аның гаиләсе әгъзалары исәнлегенә литургия һәм молебен белән дәвам итә. Аннан соң һәйкәл янында хәрби парад уза. Тантана туптан, мылтыктан атулар, барабан кагу белән тәмамлана.

Урыс сугышчылары зираты, димәк, һәйкәле урнашкан җир дә, XIX йөз башында җир бүлү нәтиҗәсендә монастырь биләмәләреннән шәһәр милкене күчкән була. Ләкин шәһәр думасы һәйкәлне саклау һәм карап торуны оештырырга ашыкмый. Килгән традиция буенча, зиратны (һәм һәйкәлне) карап тору монахлар эше дип уйлыйлар ахрысы. Санкт-Петербургтан торып эшләнгән проект Казандагы үзенчәлекләрне исәпкә алмаган икән: язгы ташу сулары һәйкәлгә зур зыян сала.

1830 елны шәһәрдә башланган холера эпидемиясенә каршы хакимиятнең эшчәнлеген күзәтү өчен Казанга эчке эшләр министры граф А.А.Закревский килә. Һәйкәлнең ташландык хәлгә килгәнен күреп, графның кәефе китә. Министрның тискәре фикерен ишеткән шәһәр башлыгы Н.И.Чижов төзекләндерү эшләрен башкару өчен сәүдәгәрләрдән акча җыюны оештыра. Алай гына да түгел, шәһәр сәүдәгәрләре һәйкәлне карап торуны үз өсләренә алалар. Бу хакта графның рапортын укыгач, император Николай I шәһәр сәүдәгәрләренә рәхмәт белдерә. Патшаның шундый игътибарын күреп, сәүдәгәрләр Л.Ф.Крупеников һәм П.И.Котелов һәйкәл попечительләре булырга теләк белдерәләр.

Зур чыгымнар белән башкарылган төзекләндерүдән соң 1832 елның 2 октябрендә һәйкәл тантаналы шартларда кабат ачыла. Патша Николай I аның чиркәвенә алтын йөгертелгән көмеш савытлар бүләк итә. Һәйкәлне кабат ачу бәйрәме бик яхшылап оештырыла. Бәйрәм өч өлештән тора. Иртәнге сәгать 7 дән булачак тантананы искәртеп Благовещенск соборы чаңы тавыш бирә. Православие дин әһелләре һәм шәһәр халкы Благовещенск соборыннан һәйкәлгә кадәр крестный ход белән киләләр. Биредә аларны архиепископ, дин әһелләре һәм парадка төзелгән хәрбиләр каршы ала. Күп халык җыелган җирдә җәмәгать тәртибен хәрби губернатор С.С.Стрекалов җитәкчелегендәге шәһәр полицейскийлары саклый. Башта һәйкәлнең чиркәвендә литургия, Казанга һөҗүм вакытында һәлак булган сугышчылар хөрмәтенә панихида үтә. Гыйбадәт кылу туп һәм мылтыктан ату белән тәмамлана. Дин әһелләре таралгач, тантана 120 кешегә әзерләнгән мәҗлес

рәвешендә дәвам итә. Өстәл янында губерна түрәләре, сәүдәгәрләр утыралар. Мәҗлестән соң шәһәрдәге барлык гаскәриләрнең зур парады була.

1832 елның 10 ноябрендә Казан шәһәре думасы һәйкәлне үз карамагына алуын белдерә, һәйкәл янында каравылчы йортын тоту, каравылга отставкадагы ике унтер-офицерны яллау өчен акча бүлеп бирә. Һәйкәлне төзекләндергән сәүдәгәрләрнең хезмәтләре югары бәяләнә. Император Николай I 1833 елның 9 февраль фәрманы белән Крупениковны Владимир алтын медале, ә Котеловны лентага беркетелгән Анна алтын медале белән бүләкли.

Успен монастыре руханилары һәйкәл чиркәвендә һәр шимбәдә һәм үлгәннәрне искә алу көннәрендә гыйбадәт кыла башлыйлар. Шулай итеп һәйкәлнең чиркәве Казанның иҗтимагый һәм рухани тормышына кушыла. Казан епархиясе җитәкчесе ел дәвамында һәйкәл чиркәвендә өч гыйбадәт кылуда катнаша: 16 августта – храм бәйрәмендә, 2 октябрьдә – Казанны алган көнне һәм 29 августта – һәлак булган православие динендәге сугышчыларны искә алу көнне.

Патша Николай I, 1836 елда Казанга килгәч, һәйкәлне барып карый. 1552 елгы вакыйгалар белән кызыксына, озатып йөрүче түрәләргә шул хакта күп сораулар бирә.

1852 ел якынлаша. Казан алынуга 300 ел тула. Ул вакыттагы епархия архиепископы Григорий, тарихи елъязмаларны өйрәнеп, 2 октябрьдә, зур хәрби җиңү көнне, һәлак булганнар истәлегенә панихида үткәрүне дөрес гамәл түгел дип таба. Архиерей фикеренчә, 2 һәм 4 октябрь зур тантана көннәре, ә 3 октябрь һәлак булганнарны искә алу, хәтер көне булырга тиеш.

1852 елның 5 сентябрендәге утырышында Синод Казан архиепископының губернатор белән килештереп эшләнгән 3 көнлек тантана сценариесын раслый. Казанны алуның 300 еллык бәйрәме шәп билгеләп үтелә.

2 октябрь көнне Благовещенск соборыннан Киприан һәм Устина чиркәвенә, Казанда ачылган беренче гыйбадәтханәгә, крестный ход була. Биредә архиепископ Григорий биш архимандрит белән литургия үткәрә. Иоанн Предтенчен монастыре янындагы мәйданга җыелган гаскәриләр һәм халык алдында молебен була.

Көндезге сәгать өчтә бәйрәм шәһәр думасы бинасында дәвам итә. Мәҗлестә катнашкан чиновниклар, православие дин әһелләре, сәүдәгәрләр бер-бер артлы патша, Русия хөрмәтенә, Казанның якты киләчәге өчен, шәһәр сәүдәгәрләре, архиепископ, губернатор хөрмәтенә тостлар әйтәләр. Халык кич белән шәһәрнең баш урамы Воскресение урамына агыла. Урам гаҗәп матур итеп иллюминация утлары белән бизәлгән була.

3 октябрь, җомга көнне, һәйкәл чиркәвендә архиепископ Григорий җитәкчелегендә шәһәр дин әһелләре патша Иван Грозный һәм Казанны алганда һәлак булган «батырларның» якты истәлегенә панихида үткәрә. Сәүдәгәрләр 2 октябрь көнне парадта катнашкан солдатларны сыйлыйлар, аларга акча тараталар.

4 октябрь епархиянең баш чиркәве Благовещенск соборында литургия була. Губернатор сарае (Хәзерге Татарстан Президенты сарае) янындагы мәйданда җыелган шәһәр халкына архиепископ «изге су» бөркегәч, Кремль стеналары тирәли тәре йөртү башлана. Дин әһелләре крепостьның һәр капкасы янында туктап, Иван Грозный хөрмәтенә, патша Николай I, шәһәр һәм православие дине исәнлегенә гыйбадәт кылалар. 3 һәм 4 октябрь көннәрендә вә Воскресение урамы бизәлгән була. Халык күңел ача.

Казан алынуга 300 еллык юбилейны үткәрү хакында Синодка язган хатында архиепископ Григорий тагын ике тәкъдим белән чыга. Беренчесе – шушы тарихи датаны ел саен 3 көн дәвамында, 1852 елгы сценарий белән билгеләп үтү. Синод утырышында катнашкан митрополит һәм архи-епископлар бу фикерне хуплыйлар, ләкин дәүләт түрәсе – Синод обер-прокуроры Платонов аны расламый.

Аның каравы, архиепископ Григорийның икенче тәкъдиме тормышка аша. Император Николай I 1854 елның 12 апрелендә кул куйган указда 4 октябрь – Казанга патша Иван Грозный тантаналы рәвештә аяк баскан һәм изгеләр – могҗиза күрсәтүчеләр (чудотворец) Гурий һәм Варсонофийны искә алу (обретение святых

мощей) көне – Казан губернасындагы барлык башлангыч уку йортлары (училищелар) һәм дәүләт оешмалары өчен бәйрәм, ял көне дип игълан ителә. (Полное собрание законов Российской империи.– Собрание 2.– Т. 29.– № 28160.) Бу тәртип 1917 елга кадәр дәвам итә.

Шулай итеп, Казанны алуны билгеләп үтү тарихында берничә этап ачык күренә.

Беренче этап – 1552–1891 еллар. Патша Иван IV әмере белән Мәскәүдә Покров соборы, Казан Кремлендә Киприан һәм Устина, Спасс һәм Благовещенск чиркәүләре төзелә, һәлак булган урыс сугышчылары каберлеген карап тору һәм шәһит киткәннәр истәлегенә панихида үткәрү өчен Успен монастырена «рус зираты» янында җир бирелә һәм биредә монастырь оеша.

Икенче этап – 1592–1822 еллар. 1592 елдан чиркәү һәм дәүләт Казанны алганда һәлак булган сугышчыларны искә алу көнен рәсмиләштерә, аны үткәрүне мәҗбүри итә. Шул вакыттан бирле алар истәлегенә Казан епархиясенең барлык чиркәү-монастырьларында шәһәрне алган көнгә туры китереп панихида үткәрелә башлый, исемнәре урыс чиркәвенең зур синодигына кертелә – Русия батырлары итеп таныла, һәлак булган православие сугышчыларын искә алу көнендә аларның исемнәре Рәсәйнең барлык гыйбадәтханәләрендә кабатлана. 2 октябрь көнне епархиянең баш чиркәве Благовещенск соборыннан Казандагы беренче төзелгән гыйбадәтханәгә – Киприан һәм Устина чиркәвенә тәре йөртү була. 1595 елдан 4 октябрь көнне Русиядә Казан епархиясенең беренче җитәкчеләре, миссионерлар Гурий һәм Варсонофий хөрмәтенә һәм истәлегенә гыйбадәт кылына.

Өченче этап – 1823–1853 еллар. Казанда татарларны җиңү хөрмәтенә һәйкәл төзелгәч, 1552 елгы тарихи вакыйганы искә алуда ике үзәк барлыкка килә. Дини ритуал Кремльдә 2 һәм 4 октябрь көннәрендә элеккечә дәвам итә. 2 октябрь көнне һәйкәл чиркәвендә патша Иван Грозный һәм аның һәлак булган сугышчыларын искә алу, панихида һәм тәхеттәге патша, аның гаилә әгъзалары исәнлегенә молебен, һәйкәл янындагы мәйданда хәрби парад була. һәйкәл чиркәве кечкенә булу сәбәпле, бирегә чакы-рулы кунаклар гына – губернатор, чиновниклар, дин әһелләре, шәһәрнең берничә күренекле кешесе, беренче нәүбәттә урыс сәүдәгәрләре килә. Ә 2 һәм 4 октябрь көннәрендә Кремльдә булган рухани бәйрәмдә дин әһелләре белән күпсанлы шәһәр халкы катнаша.

Дүртенче этап – 1854–1917 еллар. Бу чорда алда язып үткән сценарийга император Николай Павловичның 1854 ел 12 апрель указы өстәлә. Хәзер инде 4 октябрь изге Гурий һәм Варсонофийны искә алу көне генә түгел, ә рәсми рәвештә патша Иван Грозныйның беренче тапкыр Казан шәһәренә аяк баскан көне – бәйрәм көне, ял көне дип игълан ителә. Тарихи хәрби җиңү һәм тарихи рухани вакыйга көннәрендә Казан губернасындагы дәүләт оешмалары һәм башлангыч мәктәпләр ял итә башлыйлар. (1874 елдан татар мәктәпләре – мәктәп һәм мәдрәсәләр Халык мәгарифе министрлыгына буйсындырыла. Формаль яктан караганда, 4 октябрь шәкертләр, хәлфәләр, мөселман дин әһелләре өчен дә ял көне, бәйрәм булып чыга инде.)

1893 елны Чистайдан Казанга күчеп килгән Гаяз Исхакый бу вакыйгаларны күргән. 1903 елны аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре басыла. Урысларның Казанны алу көнен бәйрәм итүләре Г.Исхакый повестенда да урын алган.

Әсәрнең баш герое Җәгъфәр, исән калган соңгы болгар кешесе, юкка чыккан милләтнең язма истәлекләрен җыю өчен су юлы белән Казаннан сәяхәт кыла. Күңеленнән милләт фаҗигасен кабат кичереп, кире Казанга әйләнеп кайта. Ул кайткан көн 2 октябрь булып, урысларның Печән базарындагы мәчет алдында алтын хәрефләр белән язылган «Булгарский музей» дигән вывеска беркетүләрен күрә. Г.Исхакый бодай дип дәвам итә:

«Моңарга әллә никадәр кеше җыелган иде. Ишек төбенә әллә никадәр сачәкләр ыргытылган иде. Кич яндырыр өчен әллә никадәр электрик лампалар хәзерләнгән иде. Бу көн икенче октябрь булганга, русларның Казанга керүләре бәйрәм көне мөнәсәбәте илә болгарларның мәсҗедләренең музейга әйләнү

бәйрәме шул көнгә тугры китерелгән иде. Шуның өчен бәйрәмгә әллә никадәр кеше җыелган икән...» (Гаяз Исхакый. Әсәрләр.– 15 томда.– 1 том.– Казан: Татар, китап, нәшр., 1998.– Б. 211–212).

Г.Исхакыйның бу әсәре «Казан алынуны бәйрәм итүгә татарларның мөнәсәбәте нинди булган?» – дигән сорауга да җавап бирә сыман, һәр шәхес үз чорының бер вәкиле, шул вакыттагы мәдәният, иҗтимагый фикер белән тәрбияләнә. Шәһәрдә гасырлар дәвамында бәйрәм ителгән Казанны алу көне һәр яңа буында «элек тә шулай булган, хәзер дә шулай була», дигән фәлсәфә белән кабул ителгән дисәк, ялгыш булмас. Авылда үскән татар егете Г.Исхакый да, күрәсең, аны шулай аңлаган. Талантлы язучы буларак, шушы «гадәти вакыйга» белән ул «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендәге сюжетны сиплəп җибәргән һәм тирән мәгънәле күренеш тудыруга ирешкән. Димәк, 2 октябрьдәге бәйрәм турындагы өзек язучы фантазиясе түгел, ә XX гасыр башындагы чынбарлык. Шик юк, бу бәйрәм урыслар өчен милли горурлык, тантана көне булса, татарлар өчен югалган дәүләтләрен, үз язмышларына хуҗа булып яшәгән бәхетле заманны юксыну, сагыну. Ватаннарын саклап шәһит киткән милләттәшләрен көрсенеп искә алу көне булгандыр.

1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре 4 октябрь көнне ял итүгә чик куя. Дәүләт чиркәүдән аерыла. Без бәян иткән традицияләрнең бер өлеше хәзер фәкать урыс православие чиркәве кысаларында саклана.

Мәскәү гаскәре сафларында сугышып һәлак булган мөселманнар кайда күмелгән? Гомумән, «рус зираты» дип йөртелгән туганнар каберлегендә христианнар гына күмелгәнме? Соңгы сорауны патша Николай Павловичның 1836 елның җәендә һәйкәлне карарга килгәч үзен озатып йөрүчеләргә бирүе билгеле. Успен монастыре архимандриты Гавриил аңа, тарихчы Карамзин хезмәтләренә үз фикерләрен өстәп, якынча бодай дип җавап бирә:

«Җиңүчеләрнең дошманнары мәетләрен 1–2 чакрым ташып кадерләп күмүләре мөмкин эш түгел. Казандылар киемнәре, йөз-кыяфәтләре, ир-егетләренең сөннәткә утыртылган булулары белән аерылып торганнар. Шуңа күрә мәетләрне бутау мөмкин булмаган. Патша Иван Грозный беренче тапкыр Казанга үтәсе юл үлгән кешеләр гәүдәләреннән чистартылган, рус сугышчылары мәетләре аерым, казандылар мәетләре аерым җыелган була». Урта гасырларда христиан дине белән ислам дине арасындагы дошманлыкны искә төшерсәң, ике капма-каршы диндәге кешеләрне махсус бергә күмү мөмкин түгеллеге ачык күренә. Шуңа күрә дә 1823 елда ачылган һәйкәл өстенә зур булмаган тәре куелган. Бу, билгеле, чиркәү тәресе генә түгел, ә урыс сугышчылары каберлеге өстендә урнашкан һәйкәл тәресе дә булуына шик юк. Бер сүз белән әйткәндә, XVI йөзнең икенче яртысында – XX йөз башында урыс җәмгыяте бу каберлектә христианнар гына күмелгән дип санаган, шуңа һәйкәле дә чиркәү белән эшләнгән.

**1917** елдан алып совет власте дингә каршы «сугышчан атеизм» сәясәте башлаганчыга кадәр Казанны алу бәйрәме ничек дәвам иткән? Татарлар шәһит киткән дин кардәшләре истәлегенә Хәтер көнен үткәрү тәртибен керткәннәрме? Казанны саклап һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл салу турында бәхәсләшкәннәрме? Бу сораулар махсус өйрәнүне сорыйлар.

Кешелек тарихында сугышлар күп булган. Алар хәзер дәвам итә. Берәү җиңә, икенче як җиңелә. Ләкин барлык сугышлар да ике төрлегә бүленәләр. Гадел һәм гаделсез сугышлар. Кызганычка каршы, бик еш кына Ватаннарын яклап кулларына корал алучылар җиңелгәннәр. 1552 елда казанлылар белән дә шулай булган.

Казанны алгач, беренче 5–6 елда тарихи җиңү истәлегенә 5 һәйкәл – гыйбадәтханә төзү һәм аларны кадерләп саклау, 40 ел үткәч, үтерелгән урыс сугышчылары хөрмәтенә һәм истәлегенә чиркәү һәм дәүләтнең Хәтер көнен игълан итү, XIX йөздә, вакыйгага 271 ел узгач, урыс җәмәгатьчелегенең татарларны җиңү хөрмәтенә Казанда тагын бер һәйкәл төзүләре шушы гаделсезлекнең яңа иҗтимагый-сәяси шартларда дәвам иткән бер күренеше түгелме?

Җиңүчеләр Казанны саклап һәлак булган татар сугышчылары һәм шәһәр кешеләре мәетләрен мөселманча җирләргә рөхсәт иткәннәрме? Алар кайда

күмелгән?

Ватаннары өчен җан биргән бабаларыбызга карата гаделсезлек инде 449 ел дәвам итә. Патша Русиясендә татар «инородец» булып гомер кичергәндә, коммунистлар режимы вакытында Татарстан АССР кысаларында яшәгәндә Хәтер көнен игълан итү мөмкин булмаган дип саныйк. Быел суверен Татарстан яши башлаганга 10 ел тулды. Димәк, инде ун ел шушы гаделсезлек яшәп килүдә без гаепле.

Бүгенгә Казанны алган хөрмәткә урысларның 4 һәйкәле бар (берсе – Киприан һәм Устина чиркәве хәзер исән түгел), ә татарларның бер һәйкәле дә юк дип нәтиҗә ясау гына дөрес булмас. Кешелек җәмгыятендә элементар әхлак нормалары бар. Киләчәк буыннар бәйсезлеге өчен шәһит киткәннәрне бүген яшәүчеләр кайгыртырга тиеш: Татарстанда Хәтер кенен игълан итеп, һәйкәл куеп, ул батырларның каберләрен табып.

Былтыр Советлар Союзының Икенче бөтендөнья сугышында җиңүенә 55 ел тулды. Безнең илдә бу сугышны Бөек Ватан сугышы дип атыйлар. Электр лампаларын «Ильич лампалары» дигән сыман. Шушы юбилейга Русия һәм Татарстан хөкүмәтләре махсус программа кабул иттеләр, замана авыр булса да, акча бүлеп бирделәр. Чыннан да, авыр фронт юллары үткән, хәзер хәерче хәлендә яшәгән сугыш ветераннары дәүләт тарафыннан хөрмәткә, игътибарга, кайгыртуга бик лаек.

Минем уемча, Хәтер көне ул Казанны алганда һәлак булган милләттәшләребез өчен генә түгел, ә 1552–1557 елларда Ватаннары өчен үлгән татарлар истәлегенә булырга тиеш.

1823 елда ачылган һәйкәлгә акчаның бер өлешен Русиядә хосусый милек нык тамыр җәйгән бер вакытта шәхсән патша үзе һәм хөкүмәт биргән. 1552 елда шәһит киткән милләттәшләребез истәлегенә булачак һәйкәлне төзү халык һәм иганәчеләр хисабына гына түгел, ә Казан шәһәре хакимияте һәм Татарстан хөкүмәте ярдәме белән нәтиҗәле булачак.

Үткән тарих гыйбрәтле сабак бирә. Нәтиҗә ясап хәрәкәт итәргә вакыт үтеп бара түгелме соң?